ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 декабря 2017 г. № 6370

Башкарма комитетның 2016 елның 12 июлендәге 3538 нче карары белән расланган өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итү буенча бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181 нче Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 12 июлендәге 3538 нче карары (Башкарма комитетның 2016 елның 16 сентябрендәге 4814 нче карары редакциясендә) белән расланган өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында нигезнамәгә, түбәндәге эчтәлектәге 6.1 пункт белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«6.1 Тиешле районның Башкарма комитет Хакимияте Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә һәм Социаль тәэмин итү буенча бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ЕГИССО) операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве билгеләү факты турында, шулай ук түләү сроклары һәм күләме турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә, ЕГИССОдан файдалану юлы белән алынырга мөмкин.».

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен Башкарма комитетның Үзәк районы Хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Башкарма комитетның Автозавод районы Хакимияте Башлыгы Р.М. Усмановага, Комсомол районы Хакимияте Башлыгы А.И. Кисловка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин